ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10 12 2021 г. № 1018

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 елның 12 ноябрендәге 2201 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча башлангыч гомуми,төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 елның 12 ноябрендәге 2201 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

9.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында һәм аны күрсәтүче белем бирү оешмасы турында мәгълүматның торышы «Кулланучылар хокукларын яклау турында» һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» федераль законнар таләпләренә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгариф оешмасының рәсми сайтында урнаштыру һәм мәгариф оешмасы турында мәгълүматны яңарту кагыйдәләрен раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм кайбер нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 20 октябрендәге 1802 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына туры килергә тиеш.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма матбугатта һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.Х. Муллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874